МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.05.2021 Казан ш. № под-736/21

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 5 ноябрендәге под-1158/20 номерлы боерыгы белән расланган Банкта яки башка кредит оешмасында балигълык яшенә җитмәгән баланыкы булган счетны ябу, счетта (кертемдә) булган акчаларны алу, күчерү, тоту өчен беренчел рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 5 ноябрендәге под-1158/20 номерлы боерыгы белән расланган Банкта яки башка кредит оешмасында балигълык яшенә җитмәгән баланыкы булган счетны ябу, счетта (кертемдә) булган акчаларны алу, күчерү, тоту өчен беренчел рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (В.О.Васильева) боерыкны кабул иткәннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

**Министр** **И.Г. Һадиуллин**

Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгының 20.05.2021
№ под-736/21 боерыгы белән
расланды

Банкта яки башка кредит оешмасында балигълык яшенә җитмәгән баланыкы булган счетны ябу, счетта (кертемдә) булган акчаларны алу, күчерү, тоту өчен беренчел рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Регламент атамасын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Банкта яки башка кредит оешмасында балигълык яшенә җитмәгән баланыкы булган счетны ябу, счетта (кертемдә) булган акчаларны алу, күчерү, тоту өчен беренчел рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»;

2 бүлектә:

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Законлы вәкилләр тарафыннан бирелә торган документлар:<br>1. Гариза (Регламентка 1 нче кушымта).<br>2. Законлы вәкилнең (ата-ананың, тәрбиягә алган ата-ананың, уллыкка (кызлыкка) алучының, опекунның, попечительнең) паспорты яки шәхесен таныклый торган башка документы (күчермә һәм оригинал).<br>3. Чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән туу турында таныклык һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе.<br>4. Чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән вафат булу турындагы таныклык һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе.<br>5. Балигъ булмаган бала исеменә ачылган счет реквизитлары.<br>6. Банк счеты (кертем) килешүе.<br>7. Счетта калган акча турында белешмәләр (саклык кенәгәсе, банк счетыннан өземтә).<br>14 яшен тутырган, балигъ булмаган бала түбәндәгеләрне тапшыра: | 48-ФЗ номерлы Федераль законның 19, 21 статьялары;<br>РФ Гаилә кодексының 60 статьясы;<br>РФ Гражданлык кодексының 37 статьясы;<br>«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон; |

| | | |
|---|---|---|
| | 1. Гариза (Регламентка 2 нче кушымта).<br>2. Паспорт яки балигъ булмаган баланың шәхесен таныклаучы башка документ (күчермәләре һәм оригиналы).<br>3. Законлы вәкилнең 14 яше тулган балигъ булмаган балага счетта (кертемдә) булган акчалар белән эш итүгә ризалыгы.<br>4. Банк счеты (кертем) килешүе.<br>5. Балигъ булмаган бала исеменә ачылган счет реквизитлары.<br>6. Банк счеты (кертем) килешүе.<br>7. Счетта калган акча турында белешмәләр (саклык кенәгәсе, банк счетыннан өземтә).<br>Гариза белән ата-ананың берсе генә мөрәҗәгать иткән очракта, яисә ризалык ата-ананың берсе тарафыннан гына имзаланган очракта, ата-ананың икенчесенең булмавын яки ата-ана вазыйфаларын үтәүдән белә торып читләшүен раслый торган түбәндәге документларның берәрсе тапшырыла:<br>балигъ булмаган баланың ата-анасының берәрсен ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, аны хокукка сәләтсез дип, билгесез югалган, үлгән дип тану турында законлы көченә кергән суд карары (әлеге шартлар булган очракта).<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче опека һәм попечительлек органына шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар Мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>- шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан); | |

| | | |
|---|---|---|
| | - почта юлламасы белән.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә дә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Документларның оригиналлары һәм күчермәләре (оригиналлары тикшерелгәннән соң кире кайтарыла) бирелә, нотариуста расланган документларның күчермәләрен кабул итү мөмкин | |

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе;<br>әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактлары булуын яки булмавын раслый торган белешмәләрнең һәм башка төрле документларның формаларын һәм Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактлары булуын яки булмавын раслый торган белешмәләр һәм башка төрле документларның формаларын тутыру кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 1 октябрендәге 200 номерлы боерыгы белән расланган 2 номерлы форма буенча туу турында белешмә (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан);<br>балигълык яшенә җитмәгән баланың туу турындагы таныклыгы (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан);<br>балигъ булмаган баланың ата-анасының үлүе турында таныклык (гражданлык хәле актларын теркәү | |

| | | |
|---|---|---|
| үзидарә органы яисә оешма | органнарыннан);<br>эчке эшләр органнарыннан эзләнә торган ата-ананың урнашу урыны билгеләнмәгәнлеге турында белешмә;<br>опека (попечительлек) билгеләнүе турында акт (опекуннар (попечительләр) өчен) (опека һәм попечительлек органнарыннан);<br>балигъ булмаган баланың счетында булган акчаларны тоту кирәклеген раслый торган документ:<br>белем бирү оешмасыннан коммерцияле белем алу формасы турында белешмә;<br>медицина учреждениесеннән түләүле дәвалау кирәклеге турында белешмә.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торганын да, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документлар тапшыруны;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 | |

| | | |
|---|---|---|
| | пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны | |

3 бүлекнең 3.3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

Опека һәм попечительлек органы белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактлары булуын яки булмавын раслый торган белешмәләрнең һәм башка төрле документларның формаларын һәм Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу фактлары булуын яки булмавын раслый торган белешмәләр һәм башка төрле документларның формаларын тутыру кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 1 октябрендәге 200 номерлы боерыгы белән расланган 2 номерлы форма буенча туу турында белешмә (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан);

балигълык яшенә җитмәгән баланың туу турындагы таныклыгы (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан);

балигъ булмаган баланың ата-анасының үлүе турында таныклык (гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан);

эчке эшләр органнарыннан эзләнә торган ата-ананың урнашу урыны билгеләнмәгәнлеге турында белешмә;

опека (попечительлек) билгеләнүе турында акт (опекуннар (попечительләр) өчен) (опека һәм попечительлек органнарыннан);

балигъ булмаган баланың счетында булган акчаларны тоту кирәклеген раслый торган документ:

белем бирү оешмасыннан коммерцияле белем алу формасы турында белешмә;

медицина учреждениесеннән түләүле дәвалау кирәклеге турында белешмә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.3.2 пунктында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органга җибәрелгән рәсми мөрәҗәгать тора»;

5 бүлекнең 5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, органдагы вазыйфаи затның, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^{1}$ өлешендә каралган оешмаларның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яисә хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яки

мондый төзәтмәләрне кертү чоры бозылганда, – аны теркәгән көннән башлап биш эш көне эчендә.».